Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
“Мәмәшир урта мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

Дәрестән тыш чара

Тема:

# “Якташларым-хәйриячеләр”

Үткәрде: Насибуллина Т.Д., Кукмара муниципаль районы “Мәмәшир урта мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарих укытучысы, “Туган як тарихы” берләшмәсе җитәкчесе

**Максат:**

1. Балаларга хәйриячелек, меценатлык төшенчәләре турында мәгълүмат бирү;
2. Җәмгыять өчен файдалы эшләрдә кешенең ролен, аның әһәмиятен күрсәтү;
3. Балаларның игътибарын шәфкатьлелек, меценатлык идеяләренә юнәлдерү, милли үзаң, горурлык, патриотизм хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** татар зыялылары – меценатлар – эшмәкәрләр, мәгърифәтчеләр, укымышлы, зыялы шәхесләр, руханилар, авылдашларның рәсемнәре. “Авылымның атаклы кешеләре” сәхифәләре, дәрестә сөйләнеләчәк шәхесләр турында язмалар. Шәхесләр турында мультимедиа-презентация, «Синең горурлыгың, авылым», «Хезмәт батырлары» музей экспозицияләре.

Плакат: “Танылмыйдыр кеше гәрчә тышыннан,
Танып була аны кылган эшеннән”. Дәрдмәнд.
“Узган еллар, узган айлар яфрактай төшә бара,
Кешеләрнең гомерләре эшенә күчә бара.” Ф.Яруллин.

**Үткәрү формасы:** телдән журнал. Сыйныф 4 төркемгә бүленеп эшли.

**I Кереш.** “Юкка түгел, юкка түгелдер” җыр тыңлана (Р.Хәсәнов көе, Н.Нәҗми сүз.)

**Укытучы.** Без сезнең белән Татарстаныбызның киләчәген үткәнебез аша күз алдына китерү өчен телдән журнал тыңларга җыелдык. Ул 5 биттән тора:

1. Кеше нәрсә өчен туа?
2. Кем ул меценат?
3. Төбәгебез үсешенә өлеш керткән якташларыбыз;
4. Уйла әле.
5. Без-Татарстаныбызның киләчәге.

**II Төп өлеш**

**1 бит. Кеше нәрсә өчен туа?**

**Укытучы.** Җирдә инде яшәп киткән, хәзерге көндә яшәүче һәм алдагы көндә туачак барлык кешеләргә дә кеше булып туу бәхете насыйп булган. **Сорау:** сез ничек уйлыйсыз, Кеше нәрсә өчен туа?

Укучыларның фикерләре тыңлана:

- кеше бәхет өчен, уңышлы һәм мул, тук тормыш өчен җиргә килгән;
- кеше вазифасы Ватанга хезмәт итүдә, яхшы гамәлләр кылуда, иҗади һәм кызыклы хезмәттә;
- халык әйтсә, хак әйтә: кеше, үз гомерендә, һичшиксез, йорт салырга, агач утыртырга һәм бала үстерергә тиеш.

**Укытучы.** Төрле ил һәм халыкларның бөек шәхесләре-язучылар, галимнәр, дәүләт эшлеклеләре-әлеге сорауга төрлечә җавап бирәләр. Әмма аларның бер нәрсәдә карашлары уртак: «кеше» булу — Җирдәге иң гүзәл вазифа.

**Бирем.** Менә сезнең алда язучыларның бу хакта әйтелгән фикерләре. Һәр

төркем үзенә туры килгән фикергә карата җавап әзерли.

1. Язучы М. М. Пришвин: «Җирдәге бөтен гүзәллек - Кояштан, ә бөтен яхшылык - кешедән. Кешеләр — аңлы затлар. Алар начар гамәлләр кылмаска тиеш. Җирдәге тынычлык та һәм кешеләрнең анда ничек яшәүләре дә аларның үзләреннән тора».

2. «Нәни принц» әсәренең авторы Антуан де Сент-Экзюпери: «Кеше булу — үз җаваплылыгыңны тою ул... Үз кирпечеңне куеп, синең дә тормыш төзүдә катнашуыңны аңлау».

3. Л. Н. Толстой: «Кеше башкаларга күбрәк биргән һәм үзенә азрак таләп иткән саен, ул яхшырак күренә; башкаларга азрак биргән һәм үзенә күбрәк сораган саен, ул шулкадәр начаррак була».

4. Э. Хемингуэй: «һәр кеше нинди дә булса эш өчен туа».

**Сорау:** язучылар сүзләрен сез ничек аңлыйсыз? Кешегә нинди җаваплылык йөкләнгән?

Укучыларның фикерләре тыңлана:

- кеше ашау-эчү, матур йортта көн итү, рәхәт яшәү өчен генә тумый. Кеше, дөньядагы иң аңлы зат буларак, башкаларның иминлеген кайгыртырга, Җир планетасында яшәүчеләрнең бәхетле һәм дус-тату яшәүләре өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләргә тиеш.

**2 бит. Кем ул меценат?**

**Укытучы.** Кешелеклелек, игелеклелек, миһербанлык кебек сыйфатлар халкыбызда борынгыдан ук мактала. Алар хәйриячелекнең нигезен тәшкил итәләр. Исемнәре турыдан-туры хәйриячелек белән бәйләнешле атаклы шәхесләребез бар безнең. Аларны гадәттә “меценат” дип атыйлар.

Кем ул меценат? Ул –нинди дә булса башлангычны матди яктан үз канаты астына алучы. Мондый исем астында без милләтебезнең XVIII – XIX, XX гасыр башларында яшәгән мәгърифәтчеләрен, укымышлы, зыялы шәхесләрен, эшмәкәрләрен, руханиларын кертәбез.

**Бирем.** Төркемнәргә бүленеп бирелгән хәйрияче-меценатлар турында бирелгән материаллар, музей стендларыннан файдаланып, белешмә әзерләү биреме йөкләнә.

1) эшмәкәрләр;
2) предприятие хуҗалары;
3) мәгърифәтчеләр;
4) руханилар;

**Сорау:** мондый шәхесләргә без кемнәрне кертә алыр идек, аларның илнең икътисадын, мәдәният – мәгарифен үстерүдә уйнаган рольләрен күрсәтегез.

Укучыларның җаваплары тыңлана:

Сәүдәгәр нәселе башы булып торган Муса һәм Йосыф Апанаевлар,

Үтәмишевлар, Барудилар, Гаспринский, Алафузов, Айтугановлар, Рәмиевлар, Карл Фукс язып калдырганча, ярлыларга матди ярдәм күрсәтеп, игелекле гамәлләр кылганнар, шунлыктан Муса Апанаев “мактаулы гражданин” исеменә лаек була. Ул Казан шәһәренең 2нче мәчетен тоткан, һәм ул Апанай мәчете дип аталган. Муса тагын бер мәчет төзеткән, Корбан һәм Рамазан бәйрәмнәрендә мөселманнарга матди һәм ризыклата ярдәм күрсәткән. Габдулланың Казан шәһәрендә салдырган мәчетендә бик күп татар уллары гыйлем туплаган. Шулай ук Исхак, Муса, Исмәгыйль Үтәмишевлар да үз акчаларына мәчетләр салдыралар, мәдрәсәләр тоталар, “Мөхәммәдия “ мәдрәсәсе бинасын төзетәләр. Шулай ук шагыйрь, алтын приискалары тоткан Дәрдмәнд тә ярлыларга ярдәм күрсәткән, алар тормышы хакында борчылып иҗат иткән. Г.Баруди атаклы “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә күп татар балаларына белем алу мөмкинлеге тудыра. Мәгърифәтчеләребез Ризаэтдин Фәхретдин, Г.Курсави, Җ.Бикташилар милләтебезне уятучыларитеп күрсәтергә була.

Дәүләтчелеген югалткач, татар халкы авыр һәм караңгы, катлаулы тарихи шартларда кала. Гомумән, милләт үсештән, иҗтимагый тормыштан һәм мәдәнияттән читләштерелә. Бу шартларда татар милләте, мәдәниятенең үсеше, асылда, мөселман руханилары карамагында кала. Бары алар гына, ул заманнарның бердәнбер укымышлы, белемле, зыялы сыйныфы буларак, милләтебезне саклап калучылар була. Алар татар балаларын аң-белемле итү өчен, үз акчаларына мәдрәсәләр ачканнар. Шулай ук Каюм Насыйри да Казанда мәдрәсә ача, ярлы балалары да белем ала алсын өчен, үз итеген биреп торырга, үз карандашын берничәгә бүлеп, балаларга тоттырырга мәҗбүр була. И.Гаспринский үз акчасына “Тәрҗеман” газетасы чыгара, Кырым татарларын белемле итү өчен күп көч куя.

**3 бит. Төбәгебез үсешенә өлеш керткән якташларыбыз.**

**Укытучы.** Төбәгебез халкы элек – электән эшчән, тырыш, уңган булган, шулар арасында игелекле гамәлләр кылучы, авылыбызны данлы иткән мәшһүр якташлар, авылдашларыбыз бар.

Өлкән буынның булдыклылык үрнәге буыннан – буынга күчеп, алар аны мирас итеп алган. Буыннар алмашынса да, игелекле кешеләребез һаман туа торган.

Ә бүген без шуларга якыннанрак тукталып китәрбез.

Район тарихына күз салсак, хәйриячелек традицияләре инде элек тә - 19, 20 гасыр башларында ук күзәтелеп килгән. Без барыбыз да район икътисады, мәгарифе, мәдәниятенең нигез ташларын тәшкил иткән эшмәкәрләр, мәгърифәтчеләр, мөгаллимнәрне, аларның изге гамәлләрен искә алып үтәргә тиешбез.

Еллар үткән саен вакыйгаларны бәяләү дә үзгәрә. Әле 20 еллар элек кенә тарихны сыйнфый көрәш күзлегеннән чыгып бәяләгәннәр. Гади тел белән әйткәндә, байлар тәнкыйтьләнгән, яман итеп искә алынган, ә ярлылар

кызганылган. Ә бүген исә илдә барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, без үткәннәрне күпкырлы итеп өйрәнәбез. Байларның да кирәкле һәм саваплы гамәлләре булган. (мультимедиа-презентация күрсәтелә).

Мәсәлән, эшмәкәрләр нәселе - Үтәмишевлар, бертуган Комаровлар, Родыгиннар, Вавиловлар һ.б. Алар, үз эшләре турында кайгырту белән беррәттән, төбәкләренең үсеше , аңа файда китерү турында да кайгырткан: Комаровлар һәм Родыгиннар Ош-Юмья һәм Ершовка авылларында мәктәпләр салдырганнар һәм аларны үз хисапларына асраганнар. Нырты имениесе хуҗасы Петр Тыришкин да мәгариф үсеше, укытучылар язмышы өчен борчылып, чыгышлар ясаган. Ә Үтәмишевларга килсәк, Габдулла Үтәмишев күренекле татар байлары бишлегенә кертелгән була. Ул авылында мәчет салдыра, аның каршында үз акчасына мәдрәсә тота. Гомумән, авылларда мәчетләрне без яманларга күнеккән авыл байлары төзеткән. Габдулланың Казан шәһәрендә салдырган мәчетендә бик күп татар уллары гыйлем туплаган. Аның игелекле эшләре бүген дә дәвамын таба: ул салдырган мәчет тә, уку йортлары да әлегәчә хезмәт күрсәтә. Шулай ук Исхак, Муса , Исмәгыйль Үтәмишевлар да үз акчаларына мәчетләр салдыралар, мәдрәсәләр тоталар, “Мөхәммәдия “ мәдрәсәсе бинасын төзетәләр.

Ә авыл байларына килсәк, Мәмәширдәге Түбән оч мәчетен дә 1850 елларда Гобәйдулла бай Гыйззәтуллин салдыра. Ул үз акчасына бүрәнәләр кайтартып, авыл мәхәлләсе өчен мәчет салдыра , аның каршында мәдрәсә ача. Икенчесе 1905 нче елда салынып, соңрак юкка чыга, аның урынына 90 елларда яңа мәчет салына. Бүгенге көндә дә исән мәчет 1850-60 елларда , тау башы мәчете 1905нче елларда салынган. Аның урынында бүген 1994 нче елда салынган мәчет хезмәт күрсәтә.

**4 бит. Уйла әле.**

Район икътисады нигез ташларын тәшкил иткән эшмәкәрләр, сәүдәгәрләргә карата кроссворд чишү (кушымта 2). Җавапны әйткән төркемгә балл бирелә, күп балл җыйган төркем җиңүче дип танылa.

**5 бит. Татарстаныбызның киләчәге – безнең кулларда.**

Кеше башка кешеләр тирәлегендә яши, олыгайган саен, тирәбездә кешеләр арта бара һәм шул кешеләр өчен күпме яхшылык эшләсәң, үзеңә яшәве җиңел булачак, чөнки алар да сиңа яхшылык белән җавап бирәчәк.

Игелеклелек, хәйриячелекнең башлангычлары, орлыклары безгә тумыштан салына. Хәтта сабый бала да үз әйберен янындагы мохтаҗ кеше, бала белән бүлешергә әзер. Вакытлар үтү белән, җәмгыятьтә туган хәл үсә барган баланың ул башлангычын тирәнрәк яшерергә мәҗбүр итә. Бары тик олыгаеп, акыл кергәч кенә, без яхшылык, игелек кылу турында уйлана башлыйбыз. Шулай булгач, изгелек эшләргә соңга калмас өчен ашыгыйк һәм кылган гамәлләребез изге нияттән, күңел түреннән чыккан булсын!

Ә хәзер **“Мин меценат булсам”** дигән темага практик иҗади эш башкарабыз. Ул түбәндәге бүлекләрдән торачак:

1. Минем бүгенге көндәге статусым;

2. Мин киләчәктә республиканы ничек итеп күз алдына китерәм?
3. Мин нинди юллар белән республика үсешенә өлеш кертә алам?
4. Ватаныбыз үсеше-безнең кулларда.

**III. Йомгаклау**

Кеше башка кешеләр тирәлегендә яши һәм шул кешеләр өчен күпме яхшылык эшләсәң, үзеңә яшәве җиңел булачак, чөнки алар да сиңа яхшылык белән җавап бирәчәк.

Без Татарстанда яшибез. Бу-безнең олы туган йортыбыз. Шушы йортыбызны ярату, саклау, аның үсешен тәэмин итү-һәрберебезнең бурычы. Ә үз тарихыңны, шәхесләреңне белү – халкыңа, милләтеңә карата үзе үк игелек, хәйрия үрнәге түгелмени?!

Ә мин сезгә өйгә эш тә бирмәкче булам. Сез бергәләп “Яхшылык эшлә дә, суга сал, халык белмәсә, балык белер,” дигән татар халык мәкален тема итеп алып, үзегезнең фикерләрдән торган мөрәҗәгать әзерләп, аны район газетасына тәкъдим итеп, район халкына ирештерегез. Бу сезнең бүгенге көндә игелекле хәйрия гамәле булып торачак.

Озак та үтмәс, үсеп җитәрсез, сезнең кылган гамәлләрегез дәүләтебез, халкыбыз язмышын хәл итәчәк. Шуңа күрә бүгеннән үк төшенергә кирәк.

Шул вакытта гына сез чын гражданин, үзенең гражданлык бурычын, җаваплылыгын тоючы, үз дәүләте, халкы өчен кирәкле шәхес булып җитлегәчәксез.

Бу дөньяга без килгәнбез икән, юкка түгел!
Бу дөньяда без яшибез икән, юкка түгел!

Кушымта 1.

Җыр
“Юкка түгел, юкка түгелдер.”
Р.Хәсәнов көе, Н.Нәҗми сүзләре.

Кая барма – җирдә матурлыклар,
Без – шул җирдә туып үскәннәр.
Безгә кадәр, безгә кадәр дә бит
Җиргә күпме килеп киткәннәр.
Һәркемгә дә бирелмәгәндер ул

Яшәү – күкрәүләргә тиң гомер.
Бу дөньяга без килгәнбез икән,
Юкка түгел, юкка түгелдер!

Бер үк кояш һаман караса да,
Бер үк булмый заман җилләре.
Йолдыз белән йолдыз арасында
Балкып ята кеше эзләре.

Һәркемгә дә бирелмәгәндер ул,
Яшәү – күкрәүләргә тиң гомер,
Бу дөньяда без яшибез икән,
Юкка түгел,юкка түгелдер!

Кушымта 2.

Кроссворд



| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 9 | | | | | | | | |
| | 10 | | | | | | | | | | |
| | | 11 | | | | | | | | | |
| | | 12 | | | | | | | | | |
| | | | 13 | | | | | | | | |
| 14 | | | | | | | | | | | |
| | | | | | 15 | | | | | | |
| | | | | | 16 | | | | | | |
| | | | | 17 | | | | | | | |
| | | | | | 18 | | | | | | |

1. Итек басу белән шөгыльләнүче эшмәкәр.
2. Туеш заводында нәрсә коелган?
3. Мәмәшир авылында мәчет төзеткән, 2 гильдия сәүдәгәр исеме.
4. Мәчкәрә авылында мәчет төзеткән атаклы бай исеме.
5. Мәмәшир авылында нинди предприятие эшләгән?
6. Хәзерге киез итек-киез комбинатына нигез салучы.
7. Бүгенге көндә бу байның өе нәрсә булып хезмәт итә?
8. Мәчкәрә белән Тәмәй авылы арасында Бөр елгасында Үтәмишевларның нинди предприятиесе урнашкан була?
9. Мәмәшир авылы бай тавында яшәгән 2 гильдия сәүдәгәр фамилиясе.
10. Мәчкәрә авылында атаклы эшмәкәрләр нәселе.
11. Родыгиннарның имениесе кайда урнашкан була?
12. Итек сату белән шөгыльләнүче эшмәкәр-сәүдәгәр.
13. Авыл балаларына белем бирү өчен авыл байлары нәрсә ачтырган?
14. Атаклы татар байлары Үтәмишевларның туган авыллары.
15. Кукмара төбәге нәрсә җитештерү буенча танылган?
16. Кукмара заводларында эшләнгән чәй кайнату җайланмасы.
17. Үтәмишевларның фабрикасында нәрсә җитештергәннәр?
18. Кукмарада анң бау ишү, самовар һ.б. савыт-сабалар ясау мастерское була.

Аркылы шакмакларда Мәмәшир авылының **Социалистик Хезмәт Герое** исеменә лаек булган шәхесе фамилиясе һәм исемен укырсыз.

Җаваплар:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | р | о | д | Ы | Г | и | н | | | | | | |
| | | б | а | к | Ы | р | | | | | | | |
| | | | г | ы | Й | з | з | ә | т | у | л | л | а |
| г | а | б | д | у | Л | л | а | | | | | | |
| а | р | т | е | л | Ь | | | | | | | | |
| | | | к | о | М | а | р | о | в | | | | |
| | | м | у | з | Е | Й | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Т | е | г | е | р | м | ә | н |
| | | | а | б | Д | у | л | л | и | н | | |
| | ү | т | ә | м | И | ш | е | в | | | | |
| | | р | у | д | Н | и | к | | | | | |
| | | в | а | в | И | л | о | в | | | | |
| | | | м | ә | Д | р | ә | с | ә | | | |
| м | ә | ч | к | ә | Р | ә | | | | | | |
| | | | | | И | т | е | к | | | | |
| | | | | | С | а | м | о | в | а | р | |
| | | | | п | О | с | т | а | у | | | |
| | | | | | В | о | л | о | д | и | н | |

1 бит.
Кеше нәрсә өчен туа?

# Сез ничек уйлыйсыз, Кеше нәрсә өчен туа?

1 бит.
Кеше нәрсә өчен туа?

**1. Язучы М. М. Пришвин: «Җирдәге бөтен гүзәллек - Кояштан, ә бөтен яхшылык - кешедән. Кешеләр — аңлы затлар. Алар начар гамәлләр кылмаска тиеш. Җирдәге тынычлык та һәм кешеләрнең анда ничек яшәүләре дә аларның үзләреннән тора».**
**2. «Нәни принц» әсәренең авторы Антуан де Сент-Экзюпери: «Кеше булу — үз җаваплылыгыңны тою ул... Үз кирпечеңне куеп, синең дә тормыш төзүдә катнашуыңны аңлау».**
**3. Л. Н. Толстой: «Кеше башкаларга күбрәк биргән һәм үзенә азрак таләп иткән саен, ул яхшырак күренә; башкаларга азрак биргән һәм үзенә күбрәк сораган саен, ул шулкадәр начаррак була».**
**4. Э. Хемингуэй: «Һәр кеше нинди дә булса эш өчен туа».**

**Сорау: язучылар сүзләрен сез ничек аңлыйсыз? Кешегә нинди җаваплылык йөкләнгән?**

2 бит.
Кем ул меценат?

1) эшмәкәрләр;
2) предприятие хуҗалары;
3) мәгърифәтчеләр;
4) руханилар;

**Сорау:** мондый шәхесләргә без кемнәрне кертә алыр идек, аларның илнең икътисадын, мәдәният – мәгарифен үстерүдә уйнаган рольләрен күрсәтегез.

3 бит.
Төбәгебез үсешенә өлеш керткән якташлары быз

## Район икътисады нигез ташларын тәшкил иткән эшмәкәрләр, сәүдәгәрләргә карата кроссворд



Сораулар:
1. Элек Кукмарада итек басу белән шөгыльләнүче эшмәкәр.
2. Туеш заводында нәрсә коелган?
3. Мәмәшир авылында мәчет төзеткән, 2 гильдия сәүдәгәр исеме.
4. Мәчкәрә авылында мәчет төзеткән атаклы бай исеме.
5. Мәмәшир авылында нинди предприятие эшләгән?
6. Хәзерге киез итек-киез комбинатына нигез салучы.
7. Бүгенге көндә бу байның өе нәрсә булып хезмәт итә?
8. Мәчкәрә белән Тәмәй авылы арасында Бөр елгасында Үтәмишевларның нинди предприятиесе урнашкан була?
1. Мәмәшир авылы бай тавында яшәгән 2 гильдия сәүдәгәр фамилиясе.
1. Мәчкәрә авылында атаклы эшмәкәрләр нәселе.
2. Родыгиннарның имениесе кайда урнашкан була?
3. Итек сату белән шөгыльләнүче эшмәкәр-сәүдәгәр.
4. Авыл балаларына белем бирү өчен авыл байлары нәрсә ачтырган?
5. Атаклы татар байлары Үтәмишевларның туган авыллары.
6. Кукмара төбәге нәрсә җитештерү буенча танылган?
7. Кукмара заводларында эшләнгән чәй кайнату җайланмасы.
8. Үтәмишевларның фабрикасында нәрсә җитештергәннәр?
9. Кукмарада аның бау ишү, самовар һ.б. савыт-сабалар ясау мастерское була.

Аркылы шакмакларда Мәмәшир авылының **Социалистик Хезмәт Герое** исеменә лаек булган шәхесе фамилиясе һәм исемен укырсыз.

3 бит.
Төбәгебез үсешенә өлеш керткән якташлары быз

## Җавапларыңны тикшер

родыГин
бакЫр
гыЙззәтулла
габдуЛла
артелЬ
коМаров
музЕЙ
Тегермән
абДуллин
үтәмИшев
рудНик
ваВИлов
мәДрәсә
мәчкәРә
Итек
Самовар
пОстау
Володин

Сораулар:
1. Элек Кукмарада итек басу белән шөгыльләнүче эшмәкәр.
2. Туеш заводында нәрсә коелган?
3. Мәмәшир авылында мәчет төзеткән, 2 гильдия сәүдәгәр исеме.
1. Мәчкәрә авылында мәчет төзеткән атаклы бай исеме.
2. Мәмәшир авылында нинди предприятие эшләгән?
3. Хәзерге киез итек-киез комбинатына нигез салучы.
4. Бүгенге көндә бу байның өе нәрсә булып хезмәт итә?
5. Мәчкәрә белән Тәмәй авылы арасында Бөр елгасында Үтәмишевларның нинди предприятиесе урнашкан була?
1. Мәмәшир авылы бай тавында яшәгән 2 гильдия сәүдәгәр фамилиясе.
1. Мәчкәрә авылында атаклы эшмәкәрләр нәселе.
2. Родыгиннарның имениесе кайда урнашкан була?
3. Итек сату белән шөгыльләнүче эшмәкәр-сәүдәгәр.
4. Авыл балаларына белем бирү өчен авыл байлары нәрсә ачтырган?
5. Атаклы татар байлары Үтәмишевларның туган авыллары.
6. Кукмара төбәге нәрсә җитештерү буенча танылган?
7. Кукмара заводларында эшләнгән чәй кайнату җайланмасы.
8. Үтәмишевларның фабрикасында нәрсә җитештергәннәр?
9. Кукмарада аның бау ишү, самовар һ.б. савыт-сабалар ясау мастерское була.
Аркылы шакмакларда Мәмәшир авылының **Социалистик Хезмәт Герое** исеменә лаек булган шәхесе фамилиясе һәм исемен укырсыз.

**Бу дөньяга без килгәнбез икән, юкка түгел!**
**Бу дөньяда без яшибез икән, юкка түгел!**